ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.07.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1462**

2019 нчы елда Зеленодольск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру турындагы муниципаль программага үзгәрешләр кертү хакында

2019 нчы елда балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын, мәшгульлеген оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, мәктәп һәм студентлар каникуллары вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итү максатларында, 2018 нче елның 4 нче сентябрендәге 748 нче номерлы карары нигезендә,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019нчы елда Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында», «2014 елның 19 нчы ноябрендәге 1006нчы номерлы редакциясендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслау карарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014нче елның, 7нче февралендә, 73 нче номерлы карары белән «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы раслану хакында «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасына үзгәреш кертү хакында»,Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.01.2019 ел, 201 нче номеры карары белән расланган 2019 нчы елда Зеленодольск муниципаль районы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру турындагы муниципаль программага әлеге карарның кушымтасы нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлек җитәкчесенә бу карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы

рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В. Лукаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 нчы елның 18нче июлендәге
1462 нче карарына карата
1нче номерлы кушымта

**«Программаны финанслау» программа паспортында 5нче пунктның графасына түбәндәге эчтәлекле текст өстәргә:**«Әлеге программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны тиешле финанслау финанс елына карап Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр эчендә гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыруга тотылган акчалар күләме, район бюджеты мөмкинлекләреннән, инфляция процессларыннан һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге икътисади вәзгыятьтән чыгып, анықланырга һәм төзәтмәләр кертергә мөмкин».